ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12.09.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2469**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы мәдәният муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 1900 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 23 апрелендәге 260 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 24 маендагы 361 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 19 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы мәдәният муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 1900 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы мәдәният муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 12.03.2025, №640 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Карар) 1,2,3,4,5,6 нчы кушымталары нигезендә яңа кушымтада бирелгән редакциядә расларга.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 12 сентябрендәге
2469 номерлы карарына
1 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ КИТАПХАНӘЛӘРЕ, МУЗЕЙЛАРЫ, МУЗЕЙ ТИБЫНДАГЫ БАШКА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ-ЯЛ ИТҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЯТ, СӘНГАТЬ ҺӘМ КИНЕМАТОГРАФИЯ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫНЫҢ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯ ТӨРКЕМНӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләрендә һәм мәдәният-ял итү учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләре (алга таба-Нигезләмә, мәдәният хезмәткәрләре) окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләү шартларын һәм күләмен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын тәгаенлый.

1.2. 2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәт өчен түләү системасы -федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән мәдәният хезмәткәрләренә база окладлары, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне, хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады - - мәдәният хезмәткәрләренең тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче һөнәре буенча яки җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр оклады , компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, бер календарь ай өчен билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын асылда эшләнгән вакытта башкарган өчен мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүнең билгеләп куелган күләме;

хезмәткәрнең эш хакы (хезмәте өчен түләү) - мәдәният хезмәткәренең квалификациясенә, катлаулылыгына, башкарыла торган эшнең күләменә, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

1.3. Мәдәният хезмәткәрләренең эш хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладларыннан), эш хакы ставкаларыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. 1.4. Мәдәният хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, белем алуга яисә белем турындагы документлар торгызылуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, тармакның аерымлык билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук аның уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокук барлыкка килгәндә, аның хезмәте өчен түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Зеленодольск муниципаль районында муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең җитәкчеләре:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының "Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары" бүлеген раслау турында" 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы боерыгы белән билгеләнгән белем һәм педагогик эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларны квалификация характеристикаларына туры килүгә тикшерәләр;

ел саен барлык мәдәният хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

барлык мәдәният хезмәткәрләренең эш хакы күләмен вакытында һәм дөрес

билгеләү өчен җаваплы.

## II. Мәдәният хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Билетлар тикшерүче (контролер) | 27 300 |
| Музей күзәтүчесе | 27 300 |
| "Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 30 300 |
| Кинотеатрларга, рестораннарга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 30 300 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 30 300 |
| Дискотека алып баручы | 30 300 |
| Билет кассалары мөдире | 30 300 |
| Костюмер мөдире | 30 300 |
| Аттракционның контролер-утыртучысы | 30 300 |
| Мәдәни чараларны оештыручы | 30 300 |
| Фильм фондын ремонтлау һәм реставрацияләү участогы мастеры | 30 300 |
| Экскурсияләр оештыручы | 30 300 |
| Режиссер ярдәмчесе | 30 300 |
| Бию кичәсе җитәкчесе | 30 300 |

| | |
|---|---|
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну буенча клуб җитәкчесе | 30 300 |
| "Әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме квалификация төркеме | |
| Администратор | 30 700 |
| Администратор (өлкән администратор) | 30 700 |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 30 700 |
| Оркестр артисты | 30 700 |
| Артист-вокалчы (солист) | 30 700 |
| Библиограф | 30 700 |
| Китапханәче | 30 700 |
| Әйдәп баручы библиограф | 30 700 |
| Әйдәп баручы китапханәче | 30 700 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмаларның әйдәп баручы методисты | 30 700 |
| Баш библиограф | 30 700 |
| Баш китапханәче | 30 700 |
| Аттракцион мөдире | 30 700 |
| Тавыш операторы | 30 700 |
| Кинооператор | 30 700 |
| Лектор (экскурсовод) | 30 700 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук учреждение һәм оешмалар методисты | 30 700 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияты (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар методисты | 30 700 |
| Кинопрограммалар төзү буенча методист | 30 700 |

| | |
|---|---|
| Мөхәррир (музыка мөхәррире) | 30 700 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 30 700 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияты (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар мөхәррире | 30 700 |
| Репертуар буенча мөхәррир | 30 700 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 30 700 |
| Клуб эше методикасы буенча белгеч | 30 700 |
| Исәп-саклау документлары буенча белгеч | 30 700 |
| Фольклор белгече | 30 700 |
| Экспозиция һәм күргәзмә бүлеге белгече | 30 700 |
| Фондларны саклаучы | 30 700 |
| Ут буенча рәссам | 30 700 |
| Рәссам-декоратор | 30 700 |
| Рәссам-конструктор | 30 700 |
| Рәссам-бизәүче | 30 700 |
| Рәссам-куючы | 30 700 |
| Рәссам-реставратор | 30 700 |
| Рәссам-сынчы | 30 700 |
| Рәссам-фотограф | 30 700 |
| "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары" профессиональ квалификация төркеме | |
| Балетмейстер-куючы | 31 000 |
| Фондларның баш саклаучысы | 31 000 |
| Баш рәссам | 31 000 |
| Зоопаркның ветеринария лабораториясе мөдире | 31 000 |
| Кино-һәм видеофильмнарны прокатка бирү бүлеге | 31 000 |

| | |
|---|---|
| мөдире | |
| Китапханәнең бүлек (секторы) мөдире | 31 000 |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый ук учреждение һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире | 31 000 |
| Зоопарк бүлеге (секторы) мөдире | 31 000 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | 31 000 |
| Аттракцион техникасын эксплуатацияләү бүлеге мөдире | 31 000 |
| Музейның күчмә күргәзмә мөдире | 31 000 |
| Реставрация остаханәсе мөдире | 31 000 |
| Сәнгать-бизәү остаханәсе мөдире | 31 000 |
| Тавыш режиссеры | 31 000 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 31 000 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 31 000 |
| Режиссер-куючы | 31 000 |
| Клуб формированиесе, һәвәскәрләр берләшмәсе, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксынулар клубы җитәкчесе; | 31 000 |
| Сәнгать җитәкчесе | 31 000 |

2.2. "Мәдәният, сәнгать һәм әйдәп баручы звено хезмәткәрләре вазыйфалары" һәм "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркемнәренә кертелмәгән мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Һөнәри стандарт нигезендә вазыйфа атамасы | Айлык база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| Музей предметларын саклаучы | 30 700 |
| Музей предметларын исәпкә алу буенча белгеч | 30 700 |

| | |
|---|---|
| Экскурсия алып баручы | 30 700 |
| Тәрҗемәче-гид | 30 700 |
| Баш саклаучы | 31 000 |
| Музейны исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире | 31 000 |

Өстәмә рәвештә “музей бүлеге (секторы) мөдире”, “музейны исәпкә алу бүлеге (секторы) мөдире”, “китапханәнең бүлек (секторы) мөдире”, "мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗатының фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәнияте һәм ялы) үзәге һәм башка шундый ук учреждениеләр һәм оешмалар бүлеге (секторы) мөдире", "зоопаркның бүлек (сектор) мөдире", "кино һәм видеофильмнар прокаты буенча бүлек (пункт) мөдире" һәм "сәнгать җитәкчесе" вазыйфалары буенча база окладына карата арттыру коэффициенты - 1,1 кулланыла.

## III. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

3.1. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары;

S - мәдәният хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне хезмәтнең сыйфат нәтиҗәсенә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мактаулы исемнәр булган өчен түләү;

квалификация категориясе өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр $B_{pz}$) мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керүче хезмәткәрләргә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфа оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары союзы составында автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүләр күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемгә ия булган хезмәткәрләргә аларның булуы өчен түләү хезмәткәрнең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

4.6. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикаларына ярашлы рәвештә профессиональ квалификация төркемнәре киселешендә аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләре бирү каралган белгечлекләр буенча эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә.

Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфа оклады;

$D_{kk}$-квалификация категориясе өчен өстәмә түләү күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 1 нче таблицада китерелгән.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясен төзегән орган (учреждение) боерыгы датасына нигезләнеп башкарыла.

1 нче таблица

**Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Әйдәп баручы звенога караган мәдәнияте хезмәткәрләре вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме | |
| 2 квалификация категориясе | 2 |
| 1 квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе, шулай ук "баш" яки "әйдәп баручы" исемнәре белән билгеләнгән вазыйфалар | 6 |

4.7. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш озынлыгына карап һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфа окладды;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

Профиль буенча стажга өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |

| | | |
|---|---|---|
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.8. Эш вакыты вазыйфа буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

4.9. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү), стажны раслый торган документлар учреждениедә булган очракта, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкәннән соң яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

4.10. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре мәдәният хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел) хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий - локаль актлар белән раслана торган мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.11. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет күрсәткечләре һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.12. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләрен гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре ($B_k$) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

$O_d$- мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфа окладлы;

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең иң чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 14 |
| Урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 22 |
| Әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы | 32 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 42 |

4.14. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр хезмәткәрләргә юбилей даталарына, аерым хөрмәт билгеләре, Рәхмәт хатлары, грамоталар, мактаулы исемнәр алуга һәм оешманың локаль норматив актларында һәм коллектив шартнамәләрендә билгеләнгән башка нигезләргә бәйле рәвештә билгеле бер вакыт аралыгында (ай, квартал, ел) бер тапкыр бирелә.

4.15. Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән, төп эш урыны һәм төп вазифа буенча мәдәният хезмәткәрләренә, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.16. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениеләренең локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.17. Авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләр ($B_{sm}$) урта, әйдәп баручы звенога карарган мәдәният сәнгать һәм кинематография һәм җитәкче составы хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренә керүче мәдәният

хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$D_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме 1 388,5 сум тәшкил итә;

S - мәдәният хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## V. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш хисапчының эш хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение җитәкчеләренең, учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларның эш хакы вазыйфаи окладлардан һәм стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрдән тора.

5.2. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең окладысы хезмәт өчен түләү төркеменә карап мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан елына бер тапкыр билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең хезмәт өчен түләү төркеме мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.

5.3. Учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларының окладлары әлеге учреждение җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләме 4 нче таблицада күрсәтелгән.

4 нче таблица

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары**

| Учреждение тибы | Айга оклад күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар | | | | | | | |

| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Китапханәләр | - | 41,5 | 49,5 | 53,5 | 57,0 | 65,5 | 71,0 | - |
| Клублар | 39,5 | 46,5 | 49,5 | 53,5 | 55,0 | 60,0 | 71,0 | - |
| Музейлар | 41,0 | 45,5 | 47,0 | 55,0 | 57,0 | 65,5 | 71,0 | - |
| Мәдәни-ял итү үзәге | - | 51,5 | 53,0 | 55,0 | - | - | - | - |
| Җирле радиотапшырулар | 38,5 | - | - | - | - | - | - | - |
| Киновидео-берләшмә | 36,0 | 41,5 | - | - | - | - | - | - |
| Башкалар | 36,0 | 53,0 | - | 54,0 | 55,0 | - | - | |

5.5. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр мәдәният учреждениесе җитәкчесенә ай саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме мәдәният учреждениесе җитәкчесенә 5 нче таблицада бирелгән.

5 нче таблица

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең башкарган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме**

| Учреждение тибы | Айга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү күләме, мең сум |
|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар |

| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Китапханәләр | - | 4,5 | 5,5 | 6,0 | 7,5 | 8,0 | 8,0 | - |
| Клублар | 4,0 | 5,0 | 5,5 | 6,0 | 6,5 | 7,5 | 8,0 | - |
| Музейлар | 4,0 | 4,5 | 5,0 | 6,5 | 7,5 | 8,0 | 8,0 | - |
| Мәдәни-ял итү үзәге | - | 5,5 | 6,0 | 6,5 | - | - | - | - |
| Җирле радиотапшырулар | 3,5 | - | - | - | - | - | - | - |
| Киновидео-берләшмә | 3,5 | 4,5 | - | - | - | - | - | - |
| Башкалар | 3,5 | 6,0 | - | 6,5 | 6,5 | - | - | |

5.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр мәдәният учреждениесе җитәкче урынбасарына, баш хисапчысына, аларның эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелә ала. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүнең чик дәрәҗәсе җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга мәдәният учреждениесе җитәкчесенең башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

5.7. Мәдәният учреждениесенең җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчылары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары һәм аларның күләм коэффициентлары мәдәният учреждениесе җитәкчесе тарафыннан раслана.

5.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр ($B_k$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_C \times K_{VK},$$

биредә:

$B_c$ - 5 нче таблицада билгеләнгән мәдәният учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыруxарактерындагы түләүләр күләме;

$K_{vk}$-сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

5.9. Мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү һәм ирешелгән максатчан күрсәткечләрне саклап калу максатларында, Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән, мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә, учреждениеләр җитәкчеләренең урынбасарларына һәм төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча баш бухгалтерларга, акчалар булган очракта, бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү рәвешендәге түләү башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме локаль актлар белән билгеләнә.

5.10. Компенсация характерындагы түләүләр муниципаль мәдәният учреждениеләренең җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчысылары өчен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация характерындагы түләүләр төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

## VI. Компенсация характерындагы түләүләр

6.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә түләүләр;

нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

6.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә тиешле финанс елына һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

6.3. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$) аерым учреждениеләрдә урта, әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография һәм җитәкче состав вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

Od- мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфа оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен тәкъдим ителә торган өстәмә түләүләр күләме**

| N т/б | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләрне билгеләү | Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Өстәмә түләүләр |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | нигезләре | | күләме, процент |
| 1. | Физик үсеш кимчелекләре (сукыр, чукрак)булган затларга хезмәт күрсәтү | урта звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы | 5 |
| 2. | Милли статуска ия булган мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә эш | әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы | 30 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 30 |
| 3. | Гамәли эштә чит телне куллану | әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфасы | 5 |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 5 |
| 4. | Милли статусы булган мәдәният учреждениеләрендә гамәли эштә ике дәүләт теле куллану<*> | әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография | 10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хезмәткәрләре вазыйфасы | |
| | | мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары | 10 |
| | | | |

6.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфаларда конкрет эш шартларын исәпкә алып, һәр оешма тарафыннан сайлап куелган профсоюз органы (яки мәдәният хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган) белән килештереп раслана торган эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр билгеләнә торган мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге.

6.5. Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә компенсация характерын түләү ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәләр күләме;

$H_{fk}$ - законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$ - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең эш хакының (база окладының) база ставкасы өчен сәгать нормасы.

Хезмәт шартлары зарарлы һәм (яисә) куркыныч булган эшләрдә эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

6.6. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм

нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VII. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

7.1. Муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

7.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны исәпләү, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә агымдагы финанс-хуҗалык эшчәнлегенә каралган акчалар исәбеннән башкарыла.

7.3. Әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел)финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләре, музейлары, музей тибындагы башка учреждениеләре һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре тарафыннан кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә бүләкләү рәвешендәге түләүләргә җибәрелә ала.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда бүләкләү рәвешендәге түләүләр хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә башкарыла.

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә,мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә, эшчеләрнең гомуми тармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләрнең гомуми тармак вазыйфаларына, мәгариф хезмәткәрләре, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренә тиешле чорда хезмәткә түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган бүләкләү рәвешендәге түләүләр күләме шушы чорда хезмәт нормасын (хезмәт

вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына "Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында»" 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч мәртәбә минималь күләменнән арта алмый.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә бүләкләү рәвешендәге түләүләр күләме Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчеләренә гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән экономиядән файдаланган өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, музейларның, башка музей тибындагы учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләре җитәкчеләренә йөкләнә.

Зеленодольск муниципаль районы
муниципаль китапханәләре, музейлары,
музей тибындагы башка учреждениеләрендә
һәм мәдәният-ял итү учреждениеләрендә
мәдәният, сәнгать һәм кинематография
хезмәткәрләре вазыйфаларының
һөнәри квалификация төркемнәре
хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү
шартлары турында нигезләмәгә
кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДАГЫ СОЮЗДАШ ҺӘМ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ БУЛГАН ӨЧЕН СТИМУЛЛАШТЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР БИРЕЛӘ ТОРГАН ИСЕМЛЕК**

| N т/б | Мактаулы исем, дәүләт бүләге атамасы |
|---|---|
| 1 | 2 |

| | |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | СССРның Халык артисты |
| 3.2. | СССРның Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган пропагандачы |
| 4.2. | Халык артисты |
| 4.3. | Атказанган артист |
| 4.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 4.5. | Халык рәссамы |
| 4.6. | Атказанган рәссам |
| 4.7. | Халык язучысы |
| 4.8. | Атказанган язучы |

| | |
|---|---|
| 4.9. | Халык шагыйре |
| 4.10. | Халык җырчысы |
| 4.11. | Халык акыны |
| 4.12. | Атказанган журналист |
| 4.13. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.15. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16. | Атказанган китапханәче |
| 4.17. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.19. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык артисты |
| 5.3. | Атказанган артист |
| 5.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5. | Халык рәссамы |
| 5.6. | Атказанган рәссам |
| 5.7. | Халык язучысы |
| 5.8. | Атказанган язучы |
| 5.9. | Халык шагыйре |
| 5.10. | Атказанган журналист |
| 5.11. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12. | Атказанган китапханәче |
| 5.13. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |

| | |
|---|---|
| 5.15. | Атказанган фән эшлеклесе |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 12 сентябрендәге
2469 номерлы карарына
2 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРУ СӘНГАТЕ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ МӘДӘНИЯТ, СӘНГАТЬ ҺӘМ КИНЕМАТОГРАФИЯ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯ ТӨРКЕМНӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районының башкару сәнгате буенча муниципаль учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, башкару сәнгате хезмәткәрләре ) хезмәткәрләрнең окладларын билгеләү тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. 2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәткә түләү системасы -башкару сәнгате хезмәткәрләренең хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүнең федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән база окладлары, вазыйфаи окладлар күләмнәрен, шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

база оклады - тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы һөнәре буенча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы башкару сәнгате хезмәткәренең оклады, компенсация, стимуллаштыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча ;

вазыйфаи оклад -компенсация, стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, календарь айда билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен ставканы исәпкә алып башкару сәнгате хезмәткәренең хезмәте өчен түләүнең билгеләнгән күләме;

хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәт хакы) - башкару сәнгате хезмәткәре башкарыла торган эшнең квалификациясенә, катлаулылыгына, күләменә,

сыйфатына һәм шартларына, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен дә кертеп, хезмәте өчен түләү;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең эш хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладларыннан), эш хакы ставкаларыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Башкару сәнгате хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирүгә, мактаулы исем бирүгә,еллык яисә башка отпускта булу чорында, аның эшкә сәләтсезлек чорында, шулай ук аның өчен уртача хезмәт хакы сакланып калган башка чорларда хезмәткә түләү күләме үзгәрүгә хокук барлыкка килгәндә, аның хезмәткә түләү күләме күрсәтелгән чорлар тәмамланганнан соң үзгәртелә.

1.5. Зеленодольск муниципаль районы башкару сәнгате муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының "Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген, "Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары" бүлеген раслау турында" 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы боерыгы белән билгеләнгән белем һәм педагогик эш стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларны квалификация характеристикаларына туры килүгә тикшерәләр;

ел саен башкару сәнгатьнең муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

башкару сәнгатенең муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренең эш хакы күләмен вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы.

## II. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

| Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| "Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Театрларның һәм концерт оешмаларының ярдәмче составы артисты | 27 300 |
| Цирк номерының ассистенты | 27 300 |
| Билетлар тикшерүче (контролер) | 27 300 |
| "Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Кинотеатрларга, ресторannarга, кафеларга һәм бию мәйданчыкларына хезмәт күрсәтүче оркестр (ансамбль) артисты | 30 300 |
| Циркта өйрәтүче (дрессировщик) | 30 300 |
| Билет кассалары мөдире | 30 300 |
| Суфлер | 30 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Циркның балет артисты | 30 300 |
| Режиссер, дирижер, балетмейстер, хормейстер ассистентлары | 30 300 |
| Костюмер мөдире | 30 300 |
| Режиссер ярдәмчесе | 30 300 |
| Сөйләм техникасы буенча репетир | 30 300 |
| "Әйдәп баручы звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 30 700 |

| | |
|---|---|
| Музыкаль комедия (оперетта), музыкаль-драматик, драма театрларында, тюзларда, курчак театрларында, циркларда хор артисты | 30 700 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Администратор, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән администраторлардан тыш | 30 700 |
| Һава гимнасты артисты | 30 700 |
| "Эквилибр" жанры артисты | 30 700 |
| Хайваннар дрессурасы жанры артисты | 30 700 |
| Жонглёр жанры артисты | 30 700 |
| Иллюзия жанры артисты | 30 700 |
| Ат дрессурасы жанры артисты | 30 700 |
| Келәм артисты, буффонад клоуны , музыкаль эксцентрик, сатирик | 30 700 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты | 30 700 |
| Спорт-акробатика жанры артисты | 30 700 |
| Опера һәм балет театрларында хор артисты | 30 700 |
| Эстрада оркестры (ансамбль) артисты - өченче - бишенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән артистлардан тыш, оркестрның барлык артистлары | 30 700 |
| Концертларда башкаручы (барлык жанрларда)артистлар , ярдәмче составтагы концерт башкаручылары артистларыннан тыш | 30 700 |
| Тавыш операторы | 30 700 |
| Репертуар буенча мөхәррир | 30 700 |
| Балет буенча репетитор | 30 700 |
| Вокал буенча репетитор | 30 700 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия (оперетта) театрларында, музыкаль-драматик театрларда, тюзаларда, курчак театрларында, | 30 700 |

| | |
|---|---|
| циркларда, концерт оешмаларында администратор, өлкән администратор | |
| Курчак театры артисты(кукловод) | 30 700 |
| Балет артисты | 30 700 |
| Җыр һәм бию ансамбле балеты , бию коллективы артисты | 30 700 |
| Драма артисты | 30 700 |
| Оркестр артисты | 30 700 |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) - беренче скрипка һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипка, альт, контрабасларның икенче пультлары, икенче флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче фагот, икенче һәм дүртенче валторна, икенче торба, икенче тромбон, вак бәрмә инструментлар, икенче арфа, рояль-челеста артисты | 30 700 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты, дүртенче һәм бишенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 30 700 |
| Җыр һәм бию ансамбле, хор коллективы артисты | 30 700 |
| Артист-вокалчы (солист) | 30 700 |
| Манеж инспекторы (тамаша алып баручы) | 30 700 |
| Вокал (балет) классы буенча концертмейстер | 30 700 |
| Мөхәррир (музыка мөхәррире) | 30 700 |
| Цирк номерлары буенча репетитор | 30 700 |
| Иҗат жанрлары буенча белгеч | 30 700 |
| Ут буенча рәссам | 30 700 |
| Бутафор-рәссам | 30 700 |
| Гример -рәссам | 30 700 |
| Рәссам-декоратор | 30 700 |

| | |
|---|---|
| Рәссам-конструктор | 30 700 |
| Театр костюмының рәссам-модельеры | 30 700 |
| Рәссам-куючы | 30 700 |
| Рәссам-сынчы | 30 700 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты-концертмейстер һәм беренче скрипка, икенче скрипка, альт, виолончель, контрабас, күрсәтелгән төркем уен коралларының пульты, агач һәм бакыр тынлы уен коралларының беренче тавышлары һәм аларның көйләүчеләре, беренче арфа, бас-тромбон, туба, литавр концертмейстеры һәм концертмейстер урынбасары | 30 700 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты - беренче скрипка һәм виолончельләрнең өченче һәм дүртенче пультлары, икенче скрипка, альт, контрабасларның икенче пультлары, икенче флейта, икенче гобой, икенче кларнет, икенче һәм дүртенче валторналар, икенче торба, икенче тромбон, кечкенә бәрмә уен кораллары (симфония, камера, эстрада-симфоник оркестрларда), флейта, гобой, фагот концертмейстерлары һәм концертмейстерлар урынбасарлары; беренче, икенче һәм өченче кларнет, валторна, саксофон, торба, тромбон, туба, кларнет, баритон, тенор, бәрмә уен кораллары, контрабаслар (тынлы оркестрларда), концертмейстерлар һәм концертмейстерлар урынбасарлары, рус халык уен коралларында (балалайка, домра, баян, гөслә, жалейка, Владимир рожогы һ. б.) виртуоз уйнаучы оркестр солистлары (халык уен кораллары оркестры өчен) | 30 700 |
| Лектор-сәнгать белгече (музыка белгече) | 30 700 |
| Баш режиссер ярдәмчесе (баш дирижер, баш балетмейстер, сәнгать җитәкчесе), труппа мөдире | 30 700 |
| Сәнгатьчә укучы – нәфис сүз остасы | 30 700 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | |

| | |
|---|---|
| Җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты, эстрада оркестры (ансамбль) артисты - әйдәп баручы концертмейстер, инструментлар төркеме җитәкчесе | 30 700 |
| Симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестр, халык уен кораллары оркестры артисты – беренче скрипкалар һәм виолончельләр концертмейстеры һәм концертмейстеры урынбасары, икенче скрипка, альт, контрабас-тромбон, туба, агач һәм бакыр тынлы уен коралларының беренче тавышлары һәм аларны көйләүчеләр, беренче арфа, литавра, рояль, гитара, аккордеон, вак бәрмә кораллар, бәрмә уен кораллары җайланмасы | 30 700 |
| "Башкару сәнгать учреждениеләре җитәкчеләре составы вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Тавыш режиссеры | 31 000 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер), икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Балетмейстер-куючы, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Иҗади коллектив , цирк конвейеры программасы директоры | 31 000 |
| Музыка бүлеге мөдире, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Сәнгать-кую бүлеге мөдире, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 31 000 |
| Режиссер-куючы, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Әдәби-драматик бүлек җитәкчесе, өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |

| | |
|---|---|
| Опера һәм балет театрларында балетмейстер- куючы | 31 000 |
| Баш балетмейстер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Баш дирижер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Баш режиссер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Баш хормейстер, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Баш рәссам, дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгәннәрдән тыш | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драматик театрларда, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыкаль һәм бию коллективларында, циркларда музыка бүлеге мөдире | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында, музыка комедия театрларында, музыка-драма театрларында, драмата театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыкаль һәм бию коллективларында, концерт залларында, циркларда әдәби-сәхнәләштерелгән бүлеге мөдире | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында режиссер-куючы | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында әдәбият-драматургия бүлеге җитәкчесе | 31 000 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Опера һәм балет театрларында, музыка комедия театрларында, музыка-драма театрларында, циркларда, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында баш балетмейстер | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыка-драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, филармония һәм концерт оешмалары составындагы симфоник, камера, тынлы оркестрларда һәм халык уен | 31 000 |

| | |
|---|---|
| кораллары оркестрларында, циркларда баш дирижер | |
| Опера һәм балет театрларында, музыка комедия театрларында, музыка-драма театрларында, филармонияләрдә һәм концерт оешмаларында, мөстәкыйль музыка һәм бию коллективларында, циркларда баш хормейстер | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында, музыкаль комедия театрларында, музыкаль-драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш режиссер | 31 000 |
| Опера һәм балет театрларында, музыка комедия театрларында, музыка-драма театрларында, драма театрларында, яшь тамашачы театрларында, курчак театрларында, циркларда баш рәссам | 31 000 |

## III. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

3.1. Башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$)түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \text{ x } S,$$

биредә:

$O_b$- әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең база оклады күләме;

S - башкару сәнгате хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә башкару сәнгате хезмәткәрен сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

осталык өчен түләүләр;

«академик» исеме булган театрларда һәм концерт учреждениеләрендә эшләгән өчен түләүләр;

хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр;

мактаулы исемнәр булган өчен түләү;

шәхси казанышлар өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү.

4.3. Осталык өчен түләүләр($B_m$) эйдәп баручы звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_m = O_d \times \frac{D_m}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_m$ - осталык өчен өстәмә түләүләр күләме.

Осталык өчен өстәмә түләүләр күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Осталык өчен өстәмә түләү күләмнәре**

| Артист категориясе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| 2 нче план артисты | 2 |
| 1 нче план артисты | 4 |
| Сәхнә алып баручысы | 6 |

4.5. Хезмәт киеренкелеге өчен түләүләр ($B_{in}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{in} = O_d \times \frac{D_{in}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{in}$ - хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Хезмәт киеренкелеге өчен өстәмә түләү күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 1 | 10 |
| | 2 | 17 |
| Әйдәп баручы звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфасы | 1 | 10 |
| | 2 | 25 |
| | 3 | 35 |
| | 4 | 40 |
| | 5 | 43 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы | 1 | 30 |
| | 2 | 60 |
| | 3 | 70 |
| | 4 | 90 |

4.6. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) башкару сәнгате хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.7. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары союзы составында автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүләр күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

"Халык артисты" һәм "Атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исемнәр өчен өстәмә түләүләр күләме 20 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзы составында союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.8. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемгә ия булган башкару сәнгате хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр булган өчен түләү, башкару сәнгате хезмәткәренең сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе буенча билгеләнә.

4.10. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш озынлыгына карап һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

Профиль буенча эш стажына өстәмә түләүләр күләме 3 таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме исеме | Стаж төркеме | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәп баручы звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфасы | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.11. Эш вакыты вазыйфа буенча эш стажына кертелә торган вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге Татарстан Республикасы мәдәният министры боерыгы белән раслана.

4.12. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү), стажны раслый торган документлар учреждениедә булган очракта, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә

торган стажга ирешкәннән соң яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре башкару сәнгате хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий - локаль актлар белән раслана торган башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.14. Башкару сәнгать хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Башкару сәнгате хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләр гамәлгә ашыру шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.15. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләрен гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

4.16. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре (Bk) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

Od - башкару сәнгате хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең иң чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 4 нче таблицада китерелгән.

4 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав | 9 |

| | |
|---|---|
| артистлары вазыйфалары | |
| Урта звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфалары | 15 |
| Әйдәп баручы звенога караган башкару сәнгате хезмәткәрләре вазыйфасы | 18 |
| Башкару сәнгате учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы | 25 |

4.17. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр башкару сәнгате хезмәткәрләренә юбилей даталары, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу белән бәйле рәвештә һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

4.18. Зеленодольск муниципаль районының башкару сәнгате муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча башкару сәнгате хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү рәвешендәге түләү бирелә. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.19. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениеләренең локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.20. Авыл җирлегендә эшләгән өчен түләүләр ($B_{sm}$) урта, әйдәп баручы звенога караган мәдәният, сәнгать һәм кинематография һәм җитәкче составындагы һөнәри квалификация төркемнәренә керүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$D_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме 1 388,5 сум тәшкил итә;

S - башкару сәнгате хезмәткәре биләп торган ставкаларның факттагы саны.

## V. Учреждение җитәкчесенең, учреждение җитәкчесе урынбасарының, баш хисапчының эш хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение җитәкчеләренең (шул исәптән сәнгать җитәкчеләренең), учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларның эш хакы вазыйфаи окладлардан һәм стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләрдән тора.

5.2. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенең окладь хезмәт өчен түләү төркеменнән чыгып гамәлгә куючы тарафыннан елына бер тапкыр билгеләнә. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенең хезмәтенә түләү төркеме башкару сәнгате учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына бәйле рәвештә билгеләнә.

5.3. Учреждение җитәкчеләре урынбасарларының һәм баш хисапчыларының окладлары әлеге учреждение җитәкчеләренең вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка түбәнрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләр хезмәте өчен түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләмнәре 5 нче таблицада китерелгән.

5 нче таблица

**Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары**

| Учреждение тибы | Айга оклад күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Театр | - | - | 55,0 | 57,0 | 60,0 | 71,0 | 71,0 | 76,5 |
| Концерт оешмалары | - | 55,0 | 60,0 | 65,5 | 71,0 | 76,5 | - | - |
| Цирк | - | 49,5 | - | - | - | 60,0 | - | - |
| Башкалар | 36,0 | 53,0 | - | 54,0 | 55,0 | - | - | |

5.5. Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр эшчәнлекнең

нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә, билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә ай саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә 6 нчы таблицада бирелгән.

6 нчы таблица

**Башкару сәнгате учреждениесе җитәкчеләренең башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме**

| Учреждение тибы | Айга башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләү күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хезмәт өчен түләү төркеме | | | | | | | |
| | хезмәткәрләрнең штат саны, ставкалар | | | | | | | |
| | 10,999 га кадәр | 11 дән 30,999 га кадәр | 31 дән 50,999 га кадәр | 51 дән 75,999 га кадәр | 76 дан 150,999 га кадәр | 151 дән 300,999 га кадәр | 301 дән 500,999 га кадәр | 501 дән артык |
| Театр | - | - | 6,5 | 7,5 | 7,5 | 8,0 | 8,0 | 8,5 |
| Концерт оешмалары | - | 6,5 | 7,5 | 8,0 | 8,0 | 8,5 | - | - |
| Цирк | - | 5,5 | - | - | - | 7,5 | - | - |
| Башкалар | 3,5 | 6,0 | - | 6,5 | 6,5 | - | - | |

5.6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесе урынбасарына, баш хисапчысына стимуллаштыру характерындагы түләүләр , локаль норматив актларда билгеләнгән нәтиҗәлелек критерийлары нигезендә, эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарларына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер еллык эш нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим йөкләмәләрне үтәгән өчен бирелә ала. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен җитәкче урынбасарына, баш хисапчыга стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең иң чик дәрәҗәсе башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесе башкарган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең 80 проценты дәрәҗәсендә билгеләнә.

5.7. Башкару сәнгать учреждениесенең җитәкчеләре, җитәкчеләр урынбасарлары һәм баш хисапчылары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге критерийлары һәм аларның күләм коэффициентлары локаль актлар белән раслана.

5.8. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр (Bk) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = B_C \times K_{VK},$$

биредә:

$B_c$ - 6 нчы таблицада билгеләнгән башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме;

$K_{vk}$-сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

5.9. Башкару сәнгате учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм , Россия Федерациясе Президентының "Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында" 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатларында, төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча учреждениеләр җитәкчеләренә (шул исәптән сәнгать), учреждениеләр җитәкчеләренең урынбасарларына һәм баш хисапчыларга, акча булган очракта, бер тапкыр бирелә торган бүләкләү рәвешендәге түләүләр башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме локаль актлар белән билгеләнә.

5.10. Компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә раслана торган компенсация характерындагы түләүләр төрләре исемлеге буенча башкару сәнгате учреждениеләре җитәкчеләре, аларның урынбасарлары һәм баш хисапчылары өчен билгеләнә.

## VI. Компенсация характерындагы түләүләр

6.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә түләүләр;

нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

6.2. Компенсация характерындагы түләүләрне, күләмнәрен һәм шартларны гамәлгә ашыру хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә һәм Зеленодольск муниципаль районы башкару сәнгатенең муниципаль учреждениеләренең хезмәткә түләү буенча расланган фонд чикләрендә коллектив килешүләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

6.3. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка аерым хезмәт шартлары булган эшләрдә эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр ($B_{kh}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

биредә:

$O_d$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең база оклады;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләргә өстәмәләр күләме;

$H_{fk}$ - законнар нигезендә компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$- Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган башкару сәнгате хезмәткәрләренең эш хакының база ставкасы (база оклады) өчен сәгать нормасы.

Хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч шартлары булган эшләрдә эшләүче башкару сәнгате хезмәткәрләренә компенсация характерындагы түләүләр хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә 4 процент күләмендә билгеләнә.

6.4. Нормаль шартларга туры килмәгән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификация буенча эшләр башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны)

берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән өчен һәм нормаль шартларга туры килмәгән башка шартларда эшләр башкарганда) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## VII. Башкару сәнгате учреждениесенең хезмәтенә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

7.1. Башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм башкару сәнгате муниципаль учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

7.2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладлар, стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы түләүләр агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә башкару сәнгате учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган акчалар исәбеннән башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең барлык хезмәткәрләренә гамәлгә ашырыла.

7.3. Зеленодольск муниципаль районы башкару сәнгате учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясен, финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларын, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, тиешле чорда (ай, квартал, ел) өчен әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән Зеленодольск муниципаль районы башкару сәнгате учреждениеләренең локаль норматив актлары нигезендә, бүләкләү рәвешендәге түләүләргә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономиясе булганда бүләкләү рәвешендәге түләүләр хезмәт өчен түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә башкарыла.

Тиешле чорда хезмәткә түләү фондын экономияләү исәбеннән башкарылган бүләкләү рәвешендәге түләү күләме Зеленодольск муниципаль районы муниципаль башкару сәнгате учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре , фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең, эшче һөнәрләренең һәм җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең, мәгариф хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләренең гомуми тармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә, шушы чорда эшләнгән хезмәт нормаларын (хезмәт бурычларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына "Хезмәт өчен түләүнең минималь күләме турында" 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең өч тапкыр минималь күләменнән арта алмый.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә бүләкләү рәвешендәге түләүләр күләме Зеленодольск муниципаль районы башкару сәнгате учреждениесе җитәкчесенә гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Зеленодольск муниципаль районының башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән экономиядән файдаланган өчен җаваплылык Зеленодольск муниципаль районының башкару сәнгате муниципаль учреждениеләренең җитәкчеләренә йөкләнә.

Зеленодольск муниципаль районының
башкару сәнгате буенча муниципаль
учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм
кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары
һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең
хезмәт өчен түләү шартлары турында
нигезләмәгә
кушымта

**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ, СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ СОСТАВЫНДАГЫ СОЮЗДАШ ҺӘМ АВТОНОМИЯЛЕ РЕСПУБЛИКАЛАРНЫҢ МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘРЕ БУЛГАН ӨЧЕН СТИМУЛЛАШТЫРУ ХАРАКТЕРЫНДАГЫ ТҮЛӘҮЛӘР БИРЕЛӘ ТОРГАН ИСЕМЛЕК**

| N т/б | Мактаулы исем, дәүләт бүләге атамасы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең Халык рәссамы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең Атказанган рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең Атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының Халык язучысы |
| 2.2. | Татарстан Республикасының Халык шагыйре |
| 2.3. | Татарстан Республикасының Халык рәссамы |
| 2.4. | Татарстан Республикасының Атказанган артисты |
| 2.5. | Татарстан Республикасының Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре | |

| | |
|---|---|
| 3.1. | СССРның Халык рәссамы |
| 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган пропагандачы |
| 4.2. | Халык рәссамы |
| 4.3. | Атказанган рәссам |
| 4.4. | Халык язучысы |
| 4.5. | Атказанган язучы |
| 4.6. | Халык шагыйре |
| 4.7. | Халык җырчысы |
| 4.8. | Халык акыны |
| 4.9. | Атказанган журналист |
| 4.10. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.11. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.12. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.13. | Атказанган китапханәче |
| 4.14. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.15. | Атказанган халык иҗаты остасы |
| 4.16. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык рәссамы |
| 5.3. | Атказанган рәссам |
| 5.4. | Халык язучысы |
| 5.5. | Атказанган язучы |
| 5.6. | Халык шагыйре |

| | |
|---|---|
| 5.7. | Атказанган журналист |
| 5.8. | Атказанган китапханәче |
| 5.9. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.10. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.11. | Атказанган фән эшлеклесе |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 12 сентябрендәге
2469 номерлы карарына
3 нче кушымта

**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ МУНИЦИПАЛЬ МӘДӘНИЯТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ ФӘННИ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘНМӘЛӘР ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ ВАЗЫЙФАЛАРЫ ҺӨНӘРИ КВАЛИФИКАЦИЯ ТӨРКЕМНӘРЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ ШАРТЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мәдәният учреждениеләрендә фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру сыйфатындагы түләүләр шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын гамәлгә кертә.

1.2. 2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

хезмәткә түләү системасы - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен федераль законнар һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән база окладлары, вазыйфаи окладлар , шулай ук компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен билгели торган нормалар җыелмасы;

база окладлы - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең окладлы;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча, календарь ай өчен хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;

хезмәткәрнең эш хакы (хезмәт өчен түләү) - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре квалификациясенә, башкарыла торган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап, хезмәт өчен түләү, шулай ук

компенсация һәм стимуллаштыру түләүләре;

компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, шул исәптән нормаль булмаган шартларда эшләгән эш өчен компенсация характерындагы башка түләүләр;

стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәп түләүләр, премияләр һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

1.3. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең эш хакы (хезмәт өчен түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлардан (вазыйфаи окладларыннан), эш хакы ставкаларыннан;

стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән;

компенсация характерындагы түләүләрдән.

1.4. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәренең профиль буенча эш стажы артуга, квалификация категориясе бирелүгә, мактаулы исем бирелүгә, фәннәр докторын яисә фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе бирелүгә бәйле рәвештә, еллык яисә башка ялда булу чорында, аның вакытлыча эшкә сәләтсезлеге чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда хезмәт өчен түләү күләмен үзгәртү хокукы булганда, аның хезмәте өчен түләү күләмнәре күрсәтелгән чорлар тәмамлангач гамәлгә ашырыла.

## II. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

| Вазыйфа атамасы | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | |
| Фәнни хезмәткәрләр | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | |
| Кече фәнни хезмәткәр | 32 000 |
| Фәнни хезмәткәр | 32 000 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Өлкән фәнни хезмәткәр | 32 900 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | |

| | |
|---|---|
| Әйдәп баручы фәнни хезмәткәр | 33 500 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Баш фәнни хезмәткәр | 34 000 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | |
| Гыйльми секретарь | 34 000 |

"Музейның кече фәнни хезмәткәре" вазыйфасын биләгән хезмәткәрләрнең база оклады күләме 33 500 сум күләмендә билгеләнә.

"Музейның фәнни хезмәткәре" һәм "музейның өлкән фәнни хезмәткәре" вазыйфаларын башкаручы хезмәткәрләрнең база окладды күләме 32 900 сум күләмендә билгеләнә.

## III. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе

3.1. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады ($O_d$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times S,$$

биредә:

$O_b$ - әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең база оклады күләме;

S - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре били торган ставкаларның факттагы саны.

## IV. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

4.1. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткәрне сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләрен стимуллаштыруга, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүгә юнәлдерелгән түләүләр керә.

4.2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

мактаулы исемнәр булган өчен түләү;

гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләүләр;

башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре;

премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр;

авыл җирлегендә эшләгән өчен түләү.

4.3. Мактаулы исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{pz}$) фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.4. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары союзы составында автономияле республикаларның мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләүләр күләме 8 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре , Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларының мактаулы исемнәре булган өчен өстәмә түләү күләме 10 процент тәшкил итә.

Стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, Советлар Социалистик Республикалары Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән.

4.5. Мактаулы исемнәр булган өчен түләү күләмнәрен билгеләү, мактаулы исем бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә, мактаулы исемнәре булган өчен түләү фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре сайлавы буенча мактаулы исемнәрнең берсе билгеләнә.

4.6. Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләүләр ($B_{usz}$)фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{usz} = O_d \times \frac{D_{usz}}{100\%},$$

биредә:

$O_d$ - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{ysz}$- гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләү күләме.

4.7. Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Гыйльми дәрәҗәләрнең һәм исемнәрнең бердәм реестрына кертелгән гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр өчен бирелә.

Гыйльми дәрәҗә булган өчен түләүләр күләмнәрен билгеләү гыйльми дәрәҗә бирү турында карар үз көченә кергән көннән башкарыла. Фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе Президиумы тарафыннан кабул ителгән көннән үз көченә керә. Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турындагы карар Югары аттестация комиссиясе Президиумы тарафыннан фәннәр кандидаты дипломын бирү турында карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Гыйльми исемнәр булган өчен түләүләр күләме гыйльми исем бирелгән көннән билгеләнә.

Гыйльми дәрәҗәсе һәм гыйльми исеме булган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә, гыйльми дәрәҗәләре һәм исемнәре булган өчен түләүләр күләме фәнни дәрәҗә һәм гыйльми исеме өчен түләүләр суммасы буларак исәпләнә.

Гыйльми дәрәҗәләре һәм исемнәре булган өчен өстәмә түләүләр күләме 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица

**Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Гыйльми дәрәҗәләр һәм исемнәр булган өчен өстәмә түләүләр билгеләү нигезе | Өстәмә түләүләр күләме, процентлар | |
|---|---|---|
| | муниципаль учреждениеләрдә | төбәк әһәмиятендәге учреждениеләрдә |
| 1 | 2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасында каралган фән тармагы буенча фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсе | 20 | 60 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасында каралган фән тармагы буенча фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсе | 10 | 30 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасында каралган белгечлек буенча профессор гыйльми исеме | 40 | 80 |
| Фәнни хезмәткәрләр белгечлекләре номенклатурасында каралган белгечлек буенча доцент гыйльми исеме | 20 | 40 |

4.8. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр (Bs) профиль буенча эш озынлыгына карап һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

биредә:

Od - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме.

Профиль буенча стажга өстәмә түләүләр күләме 2 нче таблицада китерелгән.

2 нче таблица

**Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең | 1 - 4 | 3 елдан 10 елга кадәр | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| һөнәри квалификация төркеме | | 10 елдан 15 елга кадәр | 14 |
| | | 15 елдан 20 елга кадәр | 16 |
| | | 20 елдан 25 елга кадәр | 18 |
| | | 25 елдан артык | 22 |

4.9. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмнәрен билгеләү (үзгәртү), стажны раслый торган документлар учреждениедә булган очракта, профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирә торган стажга ирешкәннән соң яисә стажны раслый торган кирәкле документ бирелгән көннән башкарыла.

4.10. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, ел) фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре күләменә йогынты ясый торган төп критерий - локаль актлар белән раслана торган фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү.

4.11. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аларның җитәкчеләре тарафыннан раслана. Фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкретkүләмнәре һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.12. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләрен гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

4.13. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләре (Bk) һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_k = O_d \times \frac{D_k}{100\%},$$

биредә:

Od - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_k$ - башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең иң чик күләме.

Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләме 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица

**Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүләрнең чик күләмнәре**

| Һөнәри квалификация төркеме атамасы | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә түләүләр күләме, процент |
|---|---|---|
| Фәнни тикшеренүләр өлкәсе фәнни хезмәткәрләре һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | 1 | 22 |
| | 2 | 22 |
| | 3 | 22 |
| | 4 | 40 |

4.14. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләр фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә юбилей даталары, аерым хөрмәтләү билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу һәм оешманың локаль норматив актларында һәм коллектив шартнамәләрдә билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

4.15. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатыннан төп эш урыны һәм төп вазыйфа буенча фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренә, акча булган очракта, бер тапкыр бүләкләү рәвешендәге түләүләр башкарыла. Күрсәтелгән максатларда түләүнең тәртибе, шартлары һәм конкрет күләме учреждениенең локаль норматив актлары белән билгеләнә.

4.16. Премия һәм башка бүләкләү рәвешендәге түләүләрне башкару күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениеләренең локаль актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

4.17. Авыл җирлегендә эшләгән өчен ($B_{sm}$) түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sm} = D_{sm} \times S,$$

биредә:

$D_{sm}$ - авыл җирендә эшләгән өчен белгечләргә түләү күләме 1 388,5 сум тәшкил итә;

S - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәре били торган ставкаларның факттагы саны.

## V. Компенсация характерындагы түләүләр

5.1. Компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләүләр;

хезмәтнең зарарлы һәм (яисә) куркыныч һәм башка махсус шартлары булган эшләрдә эшләүче фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә түләүләр;

нормаль шартларга туры килмәгән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазифаларны) берләштергәндә, эш сәгатеннән тыш эшләгән өчен, төнлә эшләгән һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда) эшләгән өчен түләүләр.

5.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләренең хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә тиешле финанс елына һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив актлар белән билгеләнә.

5.3. Эшчәнлек үзенчәлекләре өчен компенсация характерындагы түләүләр ($B_{sd}$)аерым муниципаль учреждениеләрдә фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sd} = O_d \times \frac{D_{sd}}{100\%},$$

биредә:

Od - фәнни тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{sd}$ - эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме 4 нче таблицада китерелгән.

5.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазифада конкрет эш шартларын исәпкә алып, эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнә торган фәнни

тикшеренүләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге сайланулы профсоюз органы (яисә хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итәргә вәкаләтле башка орган) белән килештереп, һәр учреждение тарафыннан раслана.

4 нче таблица

**Эшчәнлек үзенчәлеге өчен тәкъдим ителә торган өстәмә түләүләр күләме**

